КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1194

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1370 нче; 2022 ел, 9 июль, 661 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясе идарәсе бүлегенең төп консультантлары, өлкән белгечләре, Министрлыкның территориаль идарәләрендәге консультантлары, 2, 3 разрядлы өлкән белгечләре, 1 разрядлы белгечләре, Министрлыкның Үзәк территориаль идарәсенә караган махсуслаштырылган инспекциянең башлыгы, башлык урынбасары, баш белгечләре, төп белгечләре, Министрлыкның территориаль идарәләрендәге экология күзәтчелеген тәэмин итү бүлеге белгечләре – әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары.»;

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әгәр төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объекты су объектларының су саклау зоналарында яки аларның өлешләрендә урнашса, бу пунктның «а», «б», «в» пунктчалары нигезендә уртача, уртача булмаган дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиешле төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектлары шул ук эзлеклелектә шактый, уртача дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиеш.

Шактый, уртача, уртача булмаган дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиешле төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектлары, төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектын риск категорияләренә кертү турында карар кабул ителгән датага кадәр өч ел эчендә үз көченә кергән түбәндәгеләр булганда, шул ук эзлеклелектә югары, шактый, уртача дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиеш:

а) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.3, 7.4, 7.6, 8.2, 8.4, 8.6, 8.7, 8.9 статьяларында, 8.10 статьясындагы 1 өлешендә, 8.11, 8.12, 8.13, 8.14, 8.21, 8.32, 8.42, 8.44, 8.45, 14.1 һәм 19.20 статьяларында каралган административ хокук бозу кылган өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки индивидуаль эшмәкәргә карата Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан төзелгән һәм, төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектын файдаланып, эшчәнлек башкарылганда кылынган административ хокук бозу турындагы беркетмә нигезендә вазыйфаи затлар (Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге дәүләт инспекторлары) яки суд тарафыннан чыгарылган административ җәза билгеләү (кисәтү рәвешендә административ җәзадан тыш) турында карар;

б) төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектын файдаланып, хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы юридик затның вазифаи затын йә индивидуаль эшмәкәрне Россия Федерациясе Җинаять кодексының 246, 247, 250 – 255 һәм 257 статьяларында каралган җинаять кылуда гаепле дип тану карала торган гаепләү хөкеме;

в) төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектын файдаланып, эшчәнлек башкарганда шундый зыян салуга китергән административ хокук бозу кылган өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки индивидуаль эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында карар;

г) бу пунктның «а» пунктчасы нигезендә югары, шактый, уртача дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиешле төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектлары, ачыкланган, тикшерү нәтиҗәләре белән расланган мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләнгән срокта бетерелгәннән соң, шул ук эзлеклелектә шактый, уртача, уртача булмаган дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиеш.»;

2.2 пунктта «инспекция визиты, рейд тикшерүе» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Бу Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән план буенча контроль (күзәтчелек) чараларының берсен үткәрү вакыты, бирелгән риск категорияләренә карап, түбәндәгечә тәшкил итә:

югары дәрәҗәдәге риск категориясе өчен – ике елга бер тапкыр;

шактый дәрәҗәдәге риск категориясе өчен – өч елга бер тапкыр;

уртача дәрәҗәдәге риск категориясе өчен – дүрт елга бер тапкыр;

уртача булмаган дәрәҗәдәге риск категориясе өчен – биш елга бер тапкыр;

түбән дәрәҗәдәге риск категориясе өчен – үткәрелми.»;

3.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Министрлыкта мәҗбүри таләпләрне бозарга җыену яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмә булган очракта һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салган (зарар китергән) йә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салу (зарар китерү) куркынычын тудырган дип расланган мәгълүмат булмаган очракта, Министрлык контрольдә тотылучы затка карата мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү белдерә һәм аңа мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итә.»;

4.8 пунктның бишенче абзацында «сынау, инструменталь тикшерү» сүзләрен өстәргә;

VI бүлектә:

беренче абзацта «2024 ел – 20,5 процент» сүзләрен өстәргә;

өченче, бишенче, алтынчы, җиденче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаның 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. I – IV куркынычлык классы калдыкларын җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлегенә лицензия (I – IV куркынычлык классы калдыкларын җыю аларны эшкәртү, һәм (яки) утильләштерү, һәм (яки) зарарсызландыру, һәм (яки) урнаштыру урыннары буенча гамәлгә ашырылмаган очраклардан тыш).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин